Язучының «Алла» хикәясендә дә катнаш никах темасы дәвам иттерелә. Д.Заһидуллина билгеләп үткәнчә, әлеге әсәрдә символ итеп алынган атның Алла исемле булуы киная алымы ярдәмендә бирелә. Хикәядә рус хатынына өйләнгән Ахияр язмышы милләт фаҗигасе кебек күзаллана. Әсәр башында автор хуҗаның атка мөнәсәбәтен тәфсилләп тасвирлый. “Хуҗасын танып, аранда ат пошкырды. Ахияр, арата аша үрелеп, атның муенын сыйпады, бирчәйгән бармакларын аның калын ялына батырды... Ахияр сөенеченнән көлеп җибәрде. Алла да... үзенең мәхәббәтен, тугрылыгын белгертергә теләп, йомшак, җылы иреннәрен хуҗасының кырынмаган йөзенә тидерде...”[5,183]. Егет атны Пермьнең Урда авылыннан, үзе эшләгән җирдән алып кайта. Бу вакытта ирләр, егетләр урыс арасында читтә эшли торган булалар. “Күбесе анда ялгыз марҗаларга йортка керәләр... Ахияр да Урда авылының Валя исемле бер кызына ияләште”[4, б.186]. Кыз аны яратуын, аңа кияүгә чыгарга теләвен белдерә, авылга яшәргә кайтырга ризалаша. Әмма Тиреследә татарлар арасында Валя озак тора алмый, улы Петрны алып, кире Урдага кайтып китә. Ахияр ике ут эчендә кала. Ахыр чиктә, хатын хакына иманын – Алласын җуйган ир, рус арасына китәр өчен, иң кадерле җан иясе – атын Алланы сугымга сата. Алла (Илаһи) – Алла омонимнары бер-берсен көчәйтеп-үстереп килә. Әсәрдә катнаш никахлар кеше өчен изге нәрсәне дә аямый дигән фикер белдерелә. Хикәя оста каләм белән язылган. Анда ат асрауга бәйле, совет властена тәнкыйди бәя дә, татар милләтенең Рәсәйдәге урынын күрсәтү дә чагылыш тапкан. Башка хикәяләрендәге кебек үк, монда да язучы детальләрне кулану да көчле. Малайга исем кушу детале, руска өйләнгән егетнең исемен «җуюы»н аңлавы (җыр вакыйгасы) тәэсирле сурәтләнә. Татар иренең әкренләп үз позицияләреннән чигенә баруы (исем кушу, рус авылында яшәп калу, баланы чукындыру һ.б.) Г.Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» повесте белән аваздаш, чөнки ике әсәрнең дә геройлары тормышында охшашлык зур [4,б.205].

Катнаш никахлар кебек акрын гына милләтебезне инкыйразга алып баручы вакыйгаларны тасвирлап, әдипләребез милләтебез язмышына битараф булмаска, хәтта һәр кешенең үз шәхси эше генә булып күренгән кемгә өйләнү, кияүгә чыгу мәсьәләсенә дә үтә җитди, милләт язмышы югарылыгыннан карап, хәл итәргә чакыра. Монда халкыбызның таянычы булырдай гореф-гадәтләребез бар, ди алар. Милләтебез нәкъ менә шушы гореф-гадәтләребезгә нигезләнгән югары әхлак кагыйдәләренә тугры калганда гына үзен саклап кала алачак.

**Әдәбият**


1. Галиуллин Т. Мәкер: повестьлар һәм хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 302 б.
2. Габидуллина Ф.И. Образ в татарской литературе // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – Тамбов: Грамота. Ч. I. № 9 (39). 2014. – С. 32-34.
3. Исхакый Гаяз Әсәрләр. 15 томда. 2 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 462 б.
4. Заһидуллина Д. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык) – Мәгариф.– 2006. – 255 б.
5. Зәйдулла Р. Ил: хикәяләр, әдәби-публицистик мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 335 б.



**Гайнуллина Гульфия Расилевна,**

*к. филол. н., доцент кафедры татарской литературы,*
*Институт филологии и межкультурной коммуникации им. Льва Толстого К(П)ФУ*
*г.Казань, Республика Татарстан, Россия*
*e-mail: gulfiarasilevna@mail.ru*



УДК 81’373


# Ә.ЕНИКИ ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА С.СӘЙДӘШЕВ ОБРАЗЫ

# ОБРАЗ С.САЙДАШЕВА В ПУБЛИЦИСТИКЕ А.ЕНИКИ

# THE IMAGE OF S. SAIDASHEV IN THE PUBLICISM OF A. ENIKI


**Аннотация.** В статье сделана попытка рассмотрения публицистики А.Еники в ракурсе отношения к национальной культуре. Образ первого татарского профессионального композитора Салиха Сайдашева запечатлен в повести писателя «Воспоминания Гулендем», а также в статьях, посвященных истории написания повести, личности С.Сайдашева. В статьях А.Еники ставит проблему увековечения имени великого сына татарского народа.



**Ключевые слова:** публицистика, повесть, музыка, композитор



**Abstract.** The article is an attempt to address publisism of A. Eniki from the perspective of the national culture. The Image of the first professional Tatar composer Salih Saidashev is depicted in the writer’s novel “Memories of Gulendam”, and in articles devoted to the history of writing the story and the personality of Salih Saidashev. In articles

A. Eniki raises the problem of perpetuating the name of the great son of the Tatar nation.
**Keywords:** publicism, story, music, composer.

Ә.Еникинең 1960-1980 еллар публицистикасында милләт хадимнәре турында кызыклы һәм гаҗәп бай эчтәлекле язмалар бар. Әдип Г.Тукай, Г.Ибраһимов, К.Тинчурин, Ф.Әмирхан, С.Сүнчәләй, Н.Исәнбәт һ.б. милләтнең асыл улларына соклана, аларны үрнәк итеп куя.

“Бәхет мәсьәләсе” (1980) язмасында әдип Салих Сәйдәшев турында сүзен “үзе турында гел уйланырга мәҗбүр итә торган шәхес” [1, б.73], – дип башлый. “Без хаклы рәвештә Салих Сәйдәшне татар музыка сәнгатенең беренче профессиональ композиторы дибез. Ләкин Салих Сәйдәшнең татар музыкасында тоткан урыны моның белән генә чикләнми, әлбәттә” [1, б.73].

Мәгълүм булганча, Ә.Еники С.Сәйдәшев образын әдәби иҗатында да гәүдәләндерә. Әдипнең “Гөләндәм туташ хатирәсе” (1975) повесте – иҗатының таҗы – гаять озын тарихлы әсәр: “Әсәрне язуга этәргеч булган материал минем кулыма илленче елларның ахырында бер кергән иде инде. Ләкин ул чакта мин язудан тыелып торырга мәҗбүр булдым. Бары унбиш ел узгач кына ул материал минем кулыма керде һәм тәвәккәлләп язарга керештем” [1, б. 30], – дип белдерә ул 1979 елда бирелгән бер әңгәмәдә. Соңрак әсәрнең язылу-басылу тарихы әдип иҗатын өйрәнүче әдәбият белгече Ә.Мотигуллинаның Ә.Еники белән әңгәмәсе итеп бастырыла [3, б. 92]. Сөйләшү барышында Ә.Еники бу тарихны түкми-чәчми сөйләп бирә. Язмадан аңлашылганча, әдип милләт хадиме С.Сәйдәшев образын иҗади эшкәртүгә үтә дә саклык белән, аерым бер игътибар белән якын килгән: “… Анда бит тарихи шәхесләр – Кәрим Тинчурин, Солтан Габәши, Фатих Әмирхан һ.б. турында сүз бара. Минем үземне “Гөләндәм хатирәсен” язарга этәргән сәбәпләрнең берсе – Салихның яшь кенә туташны әнә шул даирәгә алып керүен күрсәтү иде” [1, б. 73]. “Әдипнең “Гөләндәм туташ хатирәсе” повестеның лейтмотивы булып татар халкының музыка сәнгатенә карата кызыксынуы үсә бару тора” [4, б. 64], – дигән фикер белдерә Ә.Мотигуллина.

Шул рәвешле, милләтнең бөек уллары турында язуга әдип һәрвакыт зур җаваплылык, олы ихтирам белән якын килә. Мәхәббәт тарихы кебек кабул ителгән повестенда автор “милли-тарихи материалга мөрәҗәгать итә” [2, б. 17]. әдәбият галиме Д.Заһидуллина фикеренә өстәп, шуны билгелик: әдип Сәйдәш исеменнән “татарның киләчәге, тарих тәгәрмәчендә үзенчәлекле юлы” [2, б. 17] турында фикер җиткерә.

С.Сәйдәшев турында язганда, әдип аңа булган мөнәсәбәтне өйрәнә, барлый: “Халык Сәйдәшне яратты, ярата һәм яратачак – бу кадәресе бәхәссез. Әмма Сәйдәшнең үзенә якын даирәләрдә аңа мөнәсәбәт бер төсле генә түгел иде” [1, б. 80], – дип борчылуын яшерми әдип. Димәк, С.Сәйдәш турындагы язмада әдип үзе яшәгән дәвердә композиторның якты истәлегенә мөнәсәбәткә бәйле проблема куя, “кайберәүләр тарафыннан композиторны тиешенчә бәяләп җиткермәү тенденциясе” [1, б. 81] кулга каләм алырга мәҗбүр итә дә инде аны: “Тенденциоз мөнәсәбәт кайчагында тирән яра сала йөрәккә – үзләре татыганнар моны яхшы беләләр” [1, .б. 81], – дип тә өстәп куя.

Ә.Еникигә Сәйдәшнең танылган еллары турында әдәби әсәр язарга киңәш итәләр, әмма ул бу эшкә тәвәккәлләми: “Сәйдәшнең инде композитор булган елларын үзем күреп белсәм дә, эшкә керешә алмадым. Үземчә болай аңлата алам: иң беренче чиратта композиторлык иҗаты миңа таныш нәрсә түгел. Дилетент булып язарга ярамый” [1, 81 б.], – ди ул. Дөрес, югарыда әйтелгән язмада Ә.Еники С.Сәйдәшнең балачагын, музыкант буларак танылу елларын, иҗади дусларын, шәхси тормышын гаҗәеп саклык һәм ихтирам белән тасвирлап яза. Язмада әдипнең музыка сәнгатенә караган уйланулары да урын алуын билгеләп үтик: “Минемчә, әгәр ялгышмасам, музыка аның һәртөрле жанрларында иҗат итүдән башланса кирәк. Ә жанрлары бик күп, кемдер шуларны белергә, шигырь язган шикелле, утырып язарга да тиеш. Әнә шундый тумыштан гаять талантлы Салих Сәйдәшевтан башлана инде безнең музыка сәнгатебез. Ул керешә музыканың төрле жанрларын иҗат итәргә, аның исеме белән килеп керә безнең музыкага марш, симфония, увертюра, ария, сюита дигән төшенчәләр” [1, 75 б.].

Ә.Еники С.Сәйдәшев шәхесенә бәйләп, шәһәрдә тәрбияләнгән татар зыялысы турында да фикер йөртә: “Сәйдәш – шәһәр баласы, үз заманының алдынгы татар зыялылары арасында үсеп җитешә, шәһәр культурасы белән сугарыла, дөньяның бай музыка сәнгате белән күпмедер таныша” [1, 77 б.] .

Шул рәвешле, Ә.Еники С.Сәйдәшевкә һәм әдәби иҗатында, һәм публицистикасында сокланып, таң калып, үрнәк итеп куеп мөрәҗәгать итә. Үз чорында әдипне татарның бөек улына булган мөнәсәбәт уйга сала, татар әдәбиятының, сәнгатенең киләчәге борчый. Сәйдәшнең бәхетен Ә.Еники “Тукай өлешенә чыккан бәхеткә” тиңли: “Хәлиткеч иң мөһиме – исемең һәм эзең буыннан буынга күчә-күчә халык күңелендә һәм хәтерендә саклануда. Үлемсез бәхет әнә шул” [1, 81 б.]. Әмирхан Еники милләткә хезмәт итү гамәлендә Тукай-Сәйдәшләргә тиңләшергә киңәш итә.

**Әдәбият**

1. Еники Ә.Н. Хәтердәге төеннәр: Мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983. – 234 б.

2. Заһидуллина Д.Ф. XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятын өйрәнү мәсъәләсе / Әмирхан

Еники һәм XX йөз татар әдәбияты. – Казан: РИЦ «Школа», 2009. – Б.13-18.
3. Мотигуллина Ә.Р. “Хатирәләр” яңарганда (Әмирхан Еникигә 85 яшь) // Татарстан. – 1994. – № 3-4. – Б.91-94.
4.Мотигуллина Ә.Р. Ә.Еникинең прототиплар дөньясы яки чынбарлыктагыча гадәти каһарманнар // Чын Мирас. – 2012. – №1. – Б. 62-65.

**Галимуллин Фоат Галимулла улы,**
*филология фәннәре докторы, профессор*
*Казан (Идел буе) федераль университеты,*
*Казань шәһәре, Татарстан, Россия*
*e-mail: aifiya_gali@rambler.ru*

УДК 82

# ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИН ҺӘМ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ: СӘЯСИ ҺӘМ ЭСТЕТИК КАРШЫЛЫКЛАР

# ГАЗИЗ ГУБАЙДУЛЛИН И ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ: ПОЛИТИЧЕСКИЕ И ЭСТЕТИЧЕСКИЕ ПРОТИВОРЕЧИЯ

# GAZIZ GUBAIDULIN AND GALIMDZHAN IBRAGIMOV: POLITICAL AND AESTHETIC CONTRADICTIONS

*Статья написана и опубликована при финансовой поддержке РГНФ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта № 15-14-16017 а (р).*

**Аннотация.** В статье рассматриваются некоторые политические и эстетические противоречия во взлядах Г. Губайдуллина и Г. Ибрагимова на жизнь и творчество Г. Кулахметова.
**Ключевые слова:** история татарской литературы, творчество Г. Колахметова, Г. Ибрагимов, Г. Губайдуллин.
**Abstract.** The article deals with some of the political and aesthetic contradictions in the views G.Gubaidullin and G. Ibragimov on the life and work of G. Kulakhmetov.
**Keywords:** history of Tatar literature, works of G. Kolahmetov, G. Ibragimov, G. Gubaidullin.

Галимҗан Ибраһимовның инкыйлабтан соңгы чынбарлыкта суллар тарафын һич каршылыксыз кабул итүе билгеле нәрсә. Бу аның каләм әһелләрен сыйнфый чыгышлары ягыннан төрле катламнарга аеруы һәм аларның арасын үзара якынайту мөмкин түгеллегенә ышануында да күренә. Җитешле тормышта яшәп күнеккән кешенең яңа шартларга бәрабәр каләм тибрәтү хокукын ул еш кына кире кагарга да мөмкин. Бу нәрсә аның Г. Гобәйдуллин тарафыннан язып бастырылган “Гафур турында истәлекләрем” исемле язмасына [1, б. 49-61] булган мөнәсәбәтендә бөтен ачыклыгы белән күренә.

Газиз – Салих исемле Казан сәүдәгәре малае. Үз тырышлыгы белән Казан университетында хокук белгечлеге алган. М. Вахитов, Ф. Әмирханнар белән яшьләрнең яшерен оешкан “Шимбә” түгәрәгендә аралашкан. “Әлислах” газетасы тирәсендә мәктәп мөгаллиме һәм драматург Гафур Коләхметов белән танышкан, Троицкига укытырга киткәнче, аның белән аралашып, дуслашып яшәгән. Газиз хәтта Гафурның сеңлесе Суфияга гашыйк та була. Әтисе бу кызга өйләнергә рөхсәт итмәгәч, соңыннанрак булачак хатыны Рабига Казакова белән танышуында һәм өйләнүендә дә Гафурның йогынтысы була. Менә шуңа күрә егерменче еллар уртасында Бакуга күчеп киткәч тә Газиз дустына мөнәсәбәтле истәлекләрен хәтердә яңарта һәм, аларны бер рәвешкә китереп, алдарак искә алынган истәлекләрен бастыра. Бу язмаларны укыган кеше Г. Коләхмәтовның ун еллык гомерен шактый эзлекле итеп күздән кичерә, аны шәхес буларак бәяләү мөмкинлеге ала.

Шунысы мөһим, Г. Гөбәйдуллин үзенең дусты Гафурны иделлаштырмыйча, бизәмичә-матурламыйча, мөмкин кадәр булганынча сурәтли. Дөресрәге, аны үзе белгән кадәр генә тасвирлый, тулысынча белүгә дәгъва кылмаганы сизелеп тора. Истәлекнең икенче бүлегенең “Гафурны мин беләм шикелле” дип башлануы да очраклы түгел. Чөнки кешене белеп бетерү мөмкин дә түгел. Г. Гобәйдуллин болай дәвам иттерә: “Бу бик серле кеше, серен беркемгә дә чишми торган адәм иде. Гафурның сәяси, иҗтимагый, фәнни фикерләрен белергә мөмкин, әмма аның үз тормышындагы фикер һәм тойгыларын белү асат эш түгел” [1, б. 51]. Шуңа карамастан, Г. Гобәйдуллин менә болай расларга җөрьәт итә: “Шулай да мин әйтә алам:

-Аны бүген минем хәтле күп белгән бар микән?” [1, б. 51].